Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Советы

Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы
**КАРАРЫ**

17 ноябрь, 2025 ел № 4

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге бюджетын карауның һәм раслауның Календарь планын раслау һәм гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге Уставының 79 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның таләпләрен исәпкә алып кабул ителгән Татарстан Республикасы бюджет кодекслары нигезендә карар бирәм:

1. 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге бюджетын карауның һәм раслауның Календарь планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге бюджеты турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге Советының 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджеты хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга (алга таба - Совет карары проекты).

3. Билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар үткәрүне оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитеты;

3.2. гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 1 декабре, 13.00 сәг;

3.3. гавами тыңлаулар урыны - Татар Казысы ав., Үзәк ур., 6 й., Татар Казысы авылы мәдәният йортының тамаша залы;

3.4. авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы күрсәтелгән Совет карары проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган адрес - Татар Казысы ав., Үзәк ур., 6й.

4. Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитетына:

4.1. билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән вакытларда Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

4.2. гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен, шулай ук эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) Совет карары проектын тапшырырга.

4.3. 2025 елның 5 декабренә кадәр Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Татар Казысы авылы, Үзәк ур., 6й. адресы буенча урнашкан

мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен урнаштырырга.

5. Советның карар проектын 2025 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча Интернет челтәрендә Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Кәримуллин

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы карары белән расланды
17 ноябрь, 2025 ел № 4

2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге бюджетын карауның һәм раслауның календарь планы

| Чараның исеме | Дата | Башкаручы |
|---|---|---|
| Бюджет турындагы карар проектын җирлек башкарма комитетына тапшыру | 2025 елның 18 ноябре | «Җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ |
| Бюджет турында карар проектын җирлек Советына кертү | 2025 елның 18 ноябре | Җирлекнең башкарма комитеты |
| Экспертиза уздыру өчен контроль-хисап палатасына тапшыру | 2025 елның 19 ноябре | Җирлек Советы |
| Татар Казысы авыл җирлеге башлыгының 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге бюджетын карауның һәм раслауның календарь планын раслау һәм гавами тыңлаулар билгеләү турында карары *(тиешле орган муниципаль хокукый акт проектын караганчы 20 көннән дә соңга калмыйча)* | 2025 елның 17 ноябре | Җирлек Советы |
| Җирлек бюджеты турындагы карар проектын бастырып чыгару *(Карар гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла)* | 2025 елның 21 ноябре | Җирлекнең башкарма комитеты |
| Җирлек бюджеты турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар (Гавами тыңлаулар утырышта каралганчы 7 көннән дә соңга калмыйча уздырыла) | 2025 елның 1 декабре | Җирлекнең башкарма комитеты |
| Татар Казысы авыл җирлеге бюджетын кабул итү | 2025 елның 10 декабре | Җирлек Советы |